Республика Татарстан

Совет Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

16.09.2022 ел Менделеевск ш. №140

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Уставының 49 статьясы нигезендә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә.
2. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документлар кабул итүне 2022 елның 23 сентябреннән 2022 елның 12 октябренә кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрергә: Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 7 йорт, 104 каб., 8 дән 17 сәгатькә кадәр, көн саен ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, 2-79-19 телефоны.
3. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе составының яртысын (4 әгъза) 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.
4. Конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2014 елның 8 октябрендәге 260 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәдә күрсәтелгән срокларда Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләрен һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советына кандидатлар турында мәгълүмат

бирергә.

5. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында хәбәрне «Менделеевские новости» -«Менделеевск яңалыклары» газеталарында бастырып чыгарга, Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән Контракт проектын Менделеевск муниципаль районының http://mendeleevsk.tatarstan.ru/ рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә

Совет рәисе Р.И. Беляев

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2022 елның 16 сентябрендәге 140 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Беляев Радмир Илдар улы | - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгы, комиссия рәисе; |
| Мисалимова Светлана Владимировна | -Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы Аппаратының кадрлар эше секторы мөдире, комиссия сәркатибе; |
| Галиева Ләйсән Камил кызы | - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгы урынбасары; |
| Зарипов Марат Мисхат улы | - 3 нче номерлы Менделеевск бермандатлы сайлау округыннан депутат, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы депутаты |